Терлегең тук булганда...

Печән җыюда сүлпәнлекнең сәбәпләре нидә?

{ 2 бит. }

Паркларны нигә үзгәртәләр?

Парклар һәм скверлар елында эшләр ничегрәк тора?

{ 2 бит. }

Сабантуйда... норма тапшырдылар

ГТО нормаларын тапшыру гадәткә кереп бара.

{ 4 бит. }

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

ГАЗЕТА 1968 ЕЛДА ХЕЗМӘТ КЫЗЫЛ БАЙРАГЫ ОРДЕНЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНДЕ

МИЛЛИ БАСМА ТИРАЖ – 2005-2008 ЕЛЛАР РЕКОРДЫ

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 80 (27491). Сишәмбе. 9 июнь, 2015 ел

БӘЙРӘМ УҢАЕННАН

Рәхмәт җыяр чак

ФӘНИЯ АРСЛАНОВА

Бер рәхмәт мең бәладән коткара, ди халкыбыз. Санап барган сурәттә, социаль хезмәткәрләргә эшләү дәверендә күпме рәхмәт сүзе ишетергә туры килә икән?

Йөрәк аша үткәргәндә генә чын күңелдән ярдәм итеп була

Кичә аларның һөнәри бәйрәмнәре иде. Шул уңайдан игелекле хезмәт ияләре Качалов исемендәге театр бинасына форумга җыелды. Моңдый җыен республикада 15 нче мәртәбә үткәрелә. Татарстан Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов социаль хезмәткәрләрнең барчасына да рәхмәт әйтте. "Эшегез бер дә җиңел түгел, 500 меңгә якын кеше сезнең ярдәмгә мохтаж. Республикада күп эшләр башкарыла, уңайлыклар тудырыла, ләкин адәм баласына гел яхшыдан-яхшы кирәк, тагын да әйбәтрәккә өметләнәләр. Заманча технологиядән тыш, яхшы мөгамәлә дә бик мөһим. Сез авыр хәлдә калганнарга ярдәм итәсез, канәгать булмаучылар да очрыйдыр. Кайбер мәсьәләләрне чишү сездән генә дә тормый, акчага да бәйледер. Тик шунысы бар: бу өлкәдә һәркем эшли алмый. Монда хезмәт итүченең күңел халәте бөтенләй икенче булырга тиеш", – диде Рөстәм Миңнеханов. Бер төркем хезмәткәр аның кулыннан дәүләт бүләкләре алды.

Алар арасында Саба районының Югары Утар авылында урнашкан акылга зәгыйфь балалар интернат йорты директоры Имаметдин абый Гәрәевнең дә булуы бик куанычлы. Аңа Россия Федерациясенең "Ватан алдындагы хезмәтләре өчен" II дәрәҗә ордены тапшырылды. Имаметдин абый – республикада мәгълүм шәхес. Аның 50 ел гомере авыру балалар янында узган. Сабыйларның тормышын җиңеләйтү өчен кулдан килгәнен дә, килмәгәнен дә эшләүче олы йөрәкле кеше ул. Кайчандыр иске генә баракларны кабул итеп алган. Ә бүгенге интернат-йортның кирпечтән төзелгән корпусларын күреп шаккатасың. Аерым тренажер залы, дәвалау-уйнау бүлмәләре, укыту, компьютер класслары, тегү остаханәсе, йокы бүлмәләре, мунча, ашханә, хәтта үзләренең мини-зоопарклары да бар. Имаметдин абыйның хәлен кайчан гына сорашсаң да (үзе дә олы яшьтә бит), онытылып, интернаттагы балалар турында сөйли башлый. Директорның хәле, кәефе, бөтен булмышы шул балаларга бәйле. Аның карамагында 80 авыру бала, тагын 30ны сыйдырышлы яңа бина төзелә икән. Имаметдин Гәрәев кул астында эшләүче хезмәткәрләр дә нечкә күңелле, мәрхәмәтле әр. Монда бер генә очраклы кеше дә юк, андыйлар килсә дә, озак тормый, үзләре китеп бара. Авыру бала карау өчен эш рәте белү генә җитми шул...

Кукмара районының "Тылсым" халыкны социаль тәэмин итү үзәгенең социаль хезмәткәре Әлфия Насыйбуллинага "Татарстанның атказанган социаль хезмәткәре" исеме бирелде. Әлфия апа 24 ел инде райондагы ялгыз әби-бабайларны карый. Эшкә урнашкан мизгелләрен искә алды. "Әбиләрне каравын карармын да, үлем-җитемнәр булганда, соңгы юлга озатуны да без оештырырга тиешме?" – дип сораган ул. "Ә кем җирләсен тагын?" – дигән җавап ишеткәч, югалып та кала. Нишлисең бит, гомер бирелгәч, үлем-җитеме дә котылгысыз, качып кала алмыйсың. Әлфия ханым шул еллар эчендә дистәләгән олы кешене, йоласына туры китереп, соңгы юлга озаткан. Бүген райондагы сигез әби, бер бабайга хезмәт күрсәтә. Ул аларның өен җыештыра, азык-төлек алып кайтып бирә, төрледән-төрле гозерләрен үти. Һәркайсында социаль хезмәткәрнең кесә телефоны бар, теләсә кайчан шалтыратаралар. "Олылар белән эшләүне авыр димәс идем. Өйгә бер тапкыр да елап кайтканны хәтерләмим. Карт-карчыкларның холык-фигылен аңларга, чын күңелдән ярдәм итәргә тырышырга кирәк. Аларның үз законы закон бит, ак дигәндә – ак диюне, кара дигәндә – кара дип әйтүне, сүзләрен бүлдермичә тыңлап бетерүне яраталар", – дип эш серен ачты Әлфия Насыйбуллина.

Әйе, социаль хезмәткәргә бер үк вакытта юрист та, икътисадчы да, дипломат та, укытучы һәм психолог та булырга туры килә. Шуңа күрә дә белгечләрне иң яхшы социаль хезмәткәр, иң яхшы психолог, иң яхшы тәрбияче, иң яхшы шәфкать туташы, инвалидларны тернәкләндерү белгече номинацияләрендә котладылар. "Иң яхшы социаль хезмәткәр" исеме номинациясендә җиңүне Чүпрәле районының гаилә һәм балаларны социаль яклау бүлеге хезмәткәре Йолдыз Мусина киләчәктә эшләргә стимул дип кабул иткән. Йолдыз ханымга төрле конфликтлы гаиләләр белән очрашырга туры килә, ул беркайчан да битарафлык күрсәтми, һәр очракны йөрәге аша үткәрә, янып йөри. Шуңа микән, бергә эшләгән хезмәттәше бервакыт: "Әй, итәкле Павел Корчагин булдың инде син", – дип әйтеп куйган. Ә ул башкача булдыра алмый, тормышы мохтаҗларга булышуга көйләнгән. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова исә бу өлкәдә озак еллар эшләп, үзләреннән күп тәҗрибә калдырган ветераннарны рәхмәт сүзләре белән искә алды.

КӨННЕН АЛГЫ

Ачылыш алдыннан

ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов үткән шимбәдә Казан янындагы Иннополис инновацион шәһәрчегендә объектлар төзүнең барышын карады. Татарстан җитәкчесе иң элек А.Попов исемендәге технопаркта (биредә – холлар, эш бүлмәләре, матбугат залы һ.б.) булды. Шуннан соң Р.Миңнеханов Иннополис университеты бинасы урнашкан университет шәһәрчеге белән танышты. Ә инде сәфәренең ахырында универсаль спорт залы, бассейны һәм душ бүлмәләре булган спорт комплексында булды. Иннополисны – Россиядә XXI гасырда төзелгән тәүге шәһәрне – рәсми ачу тантанасының нәкъ менә бүген үткәрелүен дә искәртик.

Бөтенроссия Сабан туе гөрләде

Татарстан Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов үткән якшәмбедә Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы авылында VI бөтенроссия авыл Сабан туенда катнашты. Бәйрәм алдыннан Рөстәм Миңнеханов һәм губернаторның беренче урынбасары Сергей Балыкин әлеге авылдагы кайбер социаль, мәдәни объектларны карады. Моннан тыш Татарстан җитәкчесе Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган хәрбиләр һәйкәленә чәчәкләр куйды, урта мәктәп белән танышты.

Быел бөтенроссия авыл Сабан туенда Татарстан Республикасы исеменнән Кукмара муниципаль районы вәкилләре килгән иде. Рөстәм Миңнеханов үзенең сәламләү сүзендә бәйрәмне бик әйбәт оештырган өчен губернатор Юрий Бергка рәхмәт белдереп, Оренбург өлкәсендә барлык милләт вәкилләренә, шул исәптән татарларга игътибарның зур булуын билгеләп үтте. Ул РФ Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле Михаил Бабичның бөтенроссия авыл Сабантуйларын алга таба фәкать Идел буе федераль округы территориясендә генә үткәрү идеясен хуплады. Әйтик, киләсе елда әлеге бәйрәм Ульяновск өлкәсендә уздырылачак.

(Республика авылларында, район үзәкләрендә булган Сабантуйлар хакында язмалар – газетаның 4нче битендә.)

Безгә аралашырга кирәк

Кичә ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә Орел өлкәсе губернаторы Вадим Потомский белән очрашты. Очрашу кысаларында төбәкләр арасында Сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Шуннан соң В.Потомский журналистлар белән әңгәмәсендә: "Төбәкне ничек үстерергә икәнен ТР Президентыннан өйрәнергә килдем. Өйрәнерлек әйберләр бар. Биредә әйбәт икәнен белә идем, әмма шуның кадәр әйбәт булыр дип көтмәдем", – диде. Ә инде Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Орел өлкәсе – сәнәгать, шулай ук авыл хуҗалыгы мөмкинлекләренә ия булган, әмма әлегә тиешенчә ачылмаган төбәк. "Үзебезнең машина төзү һәм нефть химиясе продукциясен таныту-урнаштыру өчен, безгә әлеге төбәкнең үсүе мөһим. Шул ук вакытта Орел өлкәсендә безгә кирәкле төзелеш машиналары, юл хуҗалыгы өчен махсус билгеләнештәге машиналар җитештерелә, агросәнәгать комплексының кайбер юнәлешләре нык үскән. Иң мөһиме – хәзер без аралашырга тиеш", – дип билгеләп үтте Татарстан җитәкчесе.

Шуннан соң Вадим Потомский белән ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев очрашты. Очрашу барышында М.Шәймиев кунакны "Мәдәни мирас: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәрчеге" мәдәни-тарихи проект һәм "Яңарыш" фондының биш еллык эшчәнлеге белән таныштырды.

Сөт бәясе кими, әмма...

Җәен сөт бәясе чама белән 4-5 сумга кими. Ник дигәндә, терлек табигый көтүлекләргә җибәрелә. Әмма шәһәр халкы өчен кибет киштәләрендә әлеге ризыкның бәясе үзгәрми. Бу хакта Татар-Информ агентлыгына Татарстан агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институтыннан хәбәр ителгән. Җәен сөтнең сыйфаты яхшыра: анда кулланучылар өчен файдалы аксым һәм микроэлементлар күбәя. Бәясенә килгәндә, институттан хәбәр ителгәнчә, җәен терлек азыгына бәйле бернинди кыенлыклар булмаса да, сөт эшкәртүчеләргә чимал бәясен ел әйләнәсендә бер үк дәрәҗәдә тоту отышлы. Бүген институт вәкилләре Тәтеш һәм Чүпрәле районнарында ясаячак чыгышларында әнә шул мәсьәләне күтәрергә ниятли.

ЯШӘЕШ

Сәламәтлек – беренче урында

Сәламәтлек Россия халкының тормыш сыйфатына йогынты ясаучы иң мөһим факторларның берсе булып кала бирә. Күптән түгел Россиякүләм халык фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) белән Bayer компаниясе тарафыннан уздырылган тикшеренү барышында респондентлар сәламәтлек төшенчәсенең әһәмиятен максималь 5 баллдан 4,78 балл белән бәяләгән.

Сораштыру барышында ил халкының 44 проценты сәламәтлегенә азык-төлек продуктлары сыйфаты белән тирә-яктагы экологик вәзгыятьнең аеруча зур йогынты ясавын белдергән. Респондентларның 46 проценты исә яңа инновацион дарулар барлыкка килү белән, сәламәтлегем тагын да какшар дип курка. Сүз уңаеннан, Россия халкы "тормыш сыйфаты" дигәндә, сәламәтлектән тыш, куркынычсызлык (4,73 балл), даими хезмәт хакы (4,68), азык-төлек сыйфаты (4,68), уңайлы торак шартлары (4,66) һәм әйләнә-тирә мохитнең чиста булуын (4,61) да күздә тота.

Шушы ук сораштыру барышында россиялеләрнең күп кенә башка мәсьәләләргә дә мөнәсәбәте ачыкланган. Әйтик, Россия халкының 73 проценты, чит илдән кертелгән авыл хуҗалыгы продукциясенә караганда, үзебездә җитештерелгәнен өстен күрә. Шул ук вакытта россиялеләрнең яртысыннан артыгы (53 проценты) кибет киштәләрендә үзебезнең продукция аз булудан зарлана. Респондентлар бу проблеманы чишү юлларын да күрсәткән. Сораштыруда катнашучыларның 40 проценты дәүләт тарафыннан дотация күләмен арттырган очракта гына Россиядә авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү үсеш алачак дип саный.

МЕНӘ ШУНДЫЙ ХӘЛЛӘР

Фотога төшү генә түгел бу...

Татарстанда рус милли хәрәкәте активистлары, мәктәпләрдәге татар теле сәгатьләрен күпсенеп, "файдалырак" фәннәр керсен дип йөргәндә, федераль үзәктәгеләр "Селфи төшерү куркынычсызлыгы" дип аталган яңа дәрес сәгатьләрен кертергә тәкъдим итә.

Соңгы арада кешеләрнең селфи төшергәндә имгәнү очраклары турында хәбәрләр күбәйде. Кемдер үзен фотога төшергәндә биеклектән егылган, кемнедер елан чаккан. Белгечләр мәктәпләрдә кесә телефоннарына үз-үзеңне фотосурәткә төшерүнең аяныч нәтиҗәләргә китерү ихтималын аңлаткан дәресләр кертергә кирәк, дип чаң суга. Һәрхәлдә бу сүзне "Куркынычсызлык өчен" дигән иҗтимагый хәрәкәт вәкилләре әйтә. Бу турыда хат РФ Мәгариф министрлыгына юлланган. Дәрес вакытында профессиональ фотографлар селфи ясау серләренә өйрәтсә, психологлар белән полиция хезмәткәрләре селфи чиреннән котылу турында нотык сөйләячәк. Кешеләрне, бигрәк тә балаларны алдан кисәтсәң, хәерлерәк дип әйтәләр. Мондый дәресләрне 1 сентябрьдән Санкт-Петербургта уздыра башларга рөхсәт сорыйлар.

РФ Мәгариф министрлыгының матбугат хезмәте, аерым селфи куркынычсызлыгы турында дәрес сәгате кирәк түгел, гомумән, төрле предметлар белән эш иткәндә, хайваннар белән аралашканда куркынычсызлык кагыйдәләренә өйрәтергә кирәк, дигән фикердә тора. Мәктәпләрдә болай да Тормыш иминлеге нигезләре укытылганын искә төшергәннәр.

Активистлар, мәктәптә аерым дәрес булмаса да, урам, парк һәм скверларда куркынычсыз селфи кагыйдәләрен аңлаткан элмә такталар куелырга тиеш, ди.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

Тотрыклана, диләр...

Россиядә инфляция кимү ягына бара, авыр вакытлар узды. Бу сүзләрне Россия банкы башлыгы Эльвира Нәбиуллина РФ Дәүләт Думасы депутатларына әйтте. Ул шулай ук икътисадый үсеш башлануын да хәбәр итте.

"Әмма икътисадны читтән кергән факторлар какшату ихтималын онытырга ярамый, – диде ул. – Инфляция алты атна дәвамында 0,1 процент дәрәҗәсендә сакланган. Бу – катлаулы чор узып барунын бер күрсәткече. Без инфляцияне контрольдә тотуга ирешә алдык. Бернинди дә читтән тәэсир итүләр булмаса, икътисад үсешен квартал саен күзәтә алачакбыз".

Росстат мәгълүматларына караганда, 2015 елның маенда инфляция, аз булса да, кимү ягына борылган. Апрельдә ул 0,5 процентны тәшкил иткән булса, майда – 0,4 процент. Елның гомуми күрсәткечен санаганда, инфляция 15,8 процентка җиткән.

Төп валюталар курсы:

USD 56,04 ▼ – 0,20

EUR 62,50 ▼ – 0,81

4604609 000131